# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче “Мамадыш” совхозы поселогында 2022 елга үзара салым кертү турында

№ 16

19.11. 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогында узган гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала,, 2022 елда 400(дүрт йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелганак чаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- “Мамадыш” совхозы поселогындагы юлларны төзекләндерү (таш, торба һәм ком кулланып юлны төзекләндерү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- «Мамадыш» совхозы поселогында каты көнкүреш калдыклары контейнерлары өчен мәйданчыклар төзү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында балалар мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру;
-“Мамадыш” совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында урамнарны яктырту объектлары урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту лампалары һәм баганалар сатып алу, аларны урнаштыру, линияләргә һәм лампаларга хезмәт күрсәтү һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү):

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

В.А. Гиззатуллина